وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә
Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз!
Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп,
төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№5 (200). 2 август 2013 / 25-рамазан-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

# Якынлашып килүче Ураза бәйрәме белән!

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**
**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Чын күңелдән барыгызны да якынлашып килүче Ураза гаете белән котлыйм!

Мөбарәк бәйрәмебездә барча дөнья мөселманнарын берләштергән Раббыбызга, сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның сәхабәләренә чиксез мактауларыбыз һәм салаватшәрифләребез булса иде!

Рамазан - мәрхәмәт, изгелек һәм ураза гыйбадәте ае. Рамазан - бәндәләрне тугры юлга юнәлткән Коръәни-Кәрим иңдерелгән ай. Барлык көннәрдән кадерле Кадер кичәсе дә - бу айда. Коръәндә болар хакында ачык язылган: "Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын. Хаста булганнар яки сәфәрдәгеләр (тотылмаган көннәре хисабынча) башка көннәрне ураза тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми. Санаулы (ураза) көннәре тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, бәлки сез шөкер итәрсез?" ("Бәкара" сүрәсе, 185 нче аять)".




Рамазан аенда ураза тотуның мөһимлеге турында Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде!) хәдисендә болай диелә: "Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар (авыз ачкандагы) шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы". Тагын бер хәдистә: "Рамазан аенда иман белән һәм савапка ирешүгә өмет баглап ураза тоткан кешенең элеккеге барча гөнаһлары да ярлыканыр", диелгән.

Барча мөселманнар мөбарәк Рамазан аенда тәравих намазларында: "Ий Раббыбыз, Сиңа гына сыенабыз, коллык итәбез, Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Барча кардәшләребезне тугры юлга күндер", - дип, ялварып, Раббыбызга сыендылар һәм илебезгә, якыннарыбызга ямьле, бәрәкәтле көннәр теләделәр. Аллага шөкер, бу мөбарәк айны ниятләребезне яхшыга юнәлтеп, начарлыктан качарга, телләребезне гайбәттән, ялганнан тыярга, тәнебезне дә, күңелебезне дә хәрәмнән арындырырга тырыштык.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә тоткан уразаларыбызны, кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, Үзенең рәхимшәфкатеннән ташламаса иде. Аллаһ исемен зикер итеп, күңелләребез белән бары Коръәнгә, иманга ашкынып үткән рамазан ае савапларын күрергә язсын. Нәфесебездән өстен калып, яхшы гамәлләр генә кылып, киләсе рамазан айларын да исән-сау, бердәм булып каршы алырга насыйп итсә иде!

**Үзәкләшкән дини оешма -**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Камил хәзрәт**
**СӘМИГУЛЛИН**

# Рамазан аеның соңгы көннәре

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдиү үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.**

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне төрле нигъмәтләр белән нигъмәтләндергән Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә иксез-чиксез рәхмәтләребез, мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тарафыннан галәмнәргә рәхмәт, мәрхәмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһеленә, сәхабәләренә барчабызның сәламнәре, салаватлары һәм һәртөрле изге догалары булса иде.

Ислам диненең хаклыгына ышанып, ислам шәригате белән гамәл кылучы мөхтәрәм мөселманнар! Әссәләәмүгаләйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Аллаһы Тәгалә бөтен айларның солтаны булган мөбарәк рамазан аенда тоткан уразаларыбызны, укыган тәравих намазларыбызны, кылган изге гамәл-гыйбадәтләребезне, догаларыбызны кабуллардан кылса иде. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә ике җомга арасында фаный дөньядан мәңгелек ахирәткә күчкән газиз дин кардәшләребезнең гөнаһларын гафу итеп, үзенең рәхмәтенә ирештерсә иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләре үзенең мөбарәк хәдисендә: "Рамазан аеның беренче ун көнлеге - Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте көннәре, икенче ун көнлеге - гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ун көнлеге - җәһәннәм утыннан котылу көннәре", - дигән (Ибне Хузәймә, Сахих). Без Аллаһның рәхмәте белән 25 нче көнгә ирештек. Рамазан аеның соңгы ун көннәре аеруча кадерле, кыйммәтле, чөнки бу айның ахырында истәлекле көннәр бар. Рамазанның 21 нче көне бөтен ислам дөньясында билгеләп үтелә торган Фәтех Мәккә көне дип атала. Бу көнне сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең 12 мең сугышчыдан торган гаскәре белән Мәккәи-Мөкәррәмә шәһәрен дингә ышанмаган мәҗүсиләр, кяферләр кулыннан азат итә һәм мөселманнарның кыйбласы булган Кәгъбәтулладан табыну өчен хезмәт иткән 365 потларны-таш сыннарны чыгарттыра. Шулай итеп, Фәтех Мәккә көнне Кәгъбәтулла фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кыла торган йортка әйләнә. Фәтех Мәккә көне ислам динендә ялганның җиңелүе, ә хакыйкатьнең җиңеп чыгу көне булып тора.

Хөрмәтле мөселманнар! Әгәр тоткан юлыбыз дөрес, ниятләребез ихлас булса, иншә Аллаһ, без дә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам һәм аның сәхабәләре кебек җиңүчеләрдән булачакбыз.

Рамазан аеның соңгы ун көнлегендә бик кыйммәтле, мөкатдәс бер кичә бар, ул - Кадер кичәсе. Мәгълүм булганча, бу изге кичәдә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәлам хәзрәтләренә Коръән иңдерә башлаган. Аллаһ Раббыбыз бу мөбарәк кичә турында Үзенең Китабында болай дип әйтә: "(1) Хакыйкать шулдыр ки, Без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек. (2) Кадер кичәсенең нәрсә икәнен син беләсеңме? (3) Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк. (4) Ул көндә фәрештәләр вә Изге Рух (Җәбраил), Раббының рөхсәте илә, Аның әмерләрен җиренә җиткерер өчен, бер-бер артлы иңеп кенә торырлар. (5) Кадер кичәсе - иминлек кичәсе - таң ата башлаганга чаклы дәвам итәр" ("Кадер" сүрәсе).




Бу сүрәдә Аллаһы Тәгалә барыбызга да Кадер кичәсенең фазыйләтләрен, өстенлекләрен, әһәмиятен күрсәтә. Кадер кичәсендә кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен, хәтта бер изге сүз өчен булса да, Аллаһ Раббыбыз савапларны күпкә арттырып бирә. Әгәр Кадер кичәсендә кылган изге гамәлләрне башка айларда, кичәләрдә кылсак, андый зур әҗер-савапларга ирешә алмас идек.

Кадер кичәсенең вакыты төгәл билгеләнмәгән. Безнең хәнәфи мәзһәбе галимнәре аны рамазан аеның 27 нче көненә каршы кич дип белдерәләр. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикяф кылган, ягъни мәчеттә торып, күп тәгать-гыйбадәтләр һәм догалар кылган. Игътикяф кылып, без үзебезнең күңелләребезне сафландырабыз, йомшартабыз, Аллаһы Тәгаләгә якынаябыз. Кодси хәдистә Аллаһ Раббыбыз әйткән: "Әгәр кеше Минем бер уч төбе кадәр якынайса, Мин аның бер кулы кадәр якынаермын. Әгәр Миңа атлап килсә, Мин аңа йөгереп килермен".

Мөхтәрәм җәмәгать! Әгәр игътикяф кылырга хәлебездән килми икән, без өйләребездә дә төнге нәфел гыйбадәтләр, истигъфарлар, догалар кылып, Кадер кичәсен каршы ала алабыз. Рәсүл Әкрам галәйһиссәлам әйткән: "Кем Аллаһка ышанып һәм савабын Аллаһтан көтеп, Кадер кичәсен гыйбадәт белән уздырса, ул кешенең гөнаһлары гафу ителер", - дигән (Бохари, Мөслим).

Әнәс (Аллаһ аннан разый булса иде!) риваять итә. Мөбарәк рамазан аенда Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безгә болай дип әйтте: "Сезгә рамазан ае килде, бу айда мең айдан да хәерлерәк булган кичә бар. Кем бу кичәдән мәхрүм булса, бөтен изгелекләрдән мәхрүм булыр. Бу кичәдән бары тик бәхетсезләр генә мәхрүм буладыр" (Әхмәд бине Хәнбәл, Муснад).

Нәфел гыйбадәтләренең фазыйләте турында икенче бер кодси хәдистә болай диелгән: "Бәндә Миңа нәфел гыйбадәтләрен кылып якынаер. Мин аны яраткач, аның ишетүче колагы, күрә торган күзе, тота торган кулы, йөри торган аягы булачакмын. Ул Миннән берәр нәрсә сораса, Мин аңа, һичшиксез, аны бирәчәкмен. Миннән яклау сораса, яклаячакмын" (Бохари).

Бу хәдисне галимнәр болай дип аңлата: Аллаһы Тәгалә өстәмә гамәлләрне, ягъни нәфел гыйбадәтләрен кылучыны үзенә якынайта һәм аны иман дәрәҗәсеннән ихсан дәрәҗәсенә күтәрә, шуның нәтиҗәсендә кеше Аллаһны күргән кебек гыйбадәт кыла башлый, аның йөрәге Аллаһка карата мәхәббәт, хөрмәт, курку белән тула. Ниһаять, Аллаһы Тәгаләне танып белү сәбәпле, ул күңел күзе белән күрә башлый. Калеб нәфес хакимлегеннән азат ителә һәм Аллаһы Тәгалә теләгәнне генә тели башлый. Шундый калебкә ия булган кеше Аллаһны искә алмыйча бернәрсә дә сөйләми, Аның боерыгыннан тыш бернәрсә дә кылмый, сөйләгәндә Аллаһның ярдәме белән сөйли, караганда Аллаһның ярдәме белән карый, берәр әйбер тотканда Аның ярдәмендә тота.

Мөхтәрәм җәмәгать! Кадер кичәсенең шундый билгеләре бар: ул кичә аяз була, артык суык та, эссе дә булмый, кар-яңгыр яумый, җил исми.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# БАЛА ЯКИ АКЫЛЫ ЗӘГЫЙФЬ КЕШЕ МИЛКЕННӘН ЗӘКЯТ ТҮЛӘРГӘ КИРӘКМЕ?

اَعُوذُ بِااللهِ مِنَ اَلشَّيْطَانِ اَلرَّجِيمِ بِسمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيم
اَلْحَمْدُ اللّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ وَالصَّلاَةُ وَالسَّلاَمُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَآلِهِ اَجْمَعِينَ



Ә аннары...

Хәнәфи мәзһәбе буенча, балигъ булмаган балалар яки акыллары зәгыйфь кешеләр милкеннән зәкят түләү важиб түгел. Сәрхаси (483 нче елда вафат), Касани (587 нче елда вафат) һәм хәнәфи мәзһәбенең башка галимнәре биргән аңлатмалар буенча, үз акылындагы һәм балигъ булган кеше зәкят түләргә тиеш. Чөнки галимнәр зәкяткә гыйбадәт кылуга караган кебек карыйлар, ә гыйбадәт кылуның төп максаты - колларын сынау. Акылы зәгыйфь кеше яки балигъ булмаган бала сынауларга дучар ителә алмый. Шуңа күрә алар зәкят түләргә тиеш түгел.

Ләкин Гайшә (радыйаллаһу ганһа) һәм Ибне Гомәр (радыйаллаһу ганһу) бала яки акылы зәгыйфь (акылдан язган) кеше милкеннән зәкят түләүне важиб дип санаганнар. Шәфигый мәзһәбе бу фикерне кабул иткән. Ләкин бу буруч бала яки акылы зәгыйфь кеше өстендә түгел, ә аларны караучылар өстендә. Шуңа күрә бала балигъ булганчы, ә акылы зәгыйфь кеше (мөмкин булган очракта) терелгәнче, аның өчен җаваплылар (опекуннар) аларның милкеннән, җаваплы кешеләр буларак, зәкят түләргә тиеш.

Балигъ булмаган балалар яки акыллары зәгыйфь кешеләр милкеннән зәкят түләнми дигән карар чыгарып, хәнәфи мәзһәбе башкалардан аерылып торган фикерне кабул итә. Бу күзлектән чыгып караганда, хәнәфи мәзһәбе буенча, зәкят түләүче кеше үз акылында һәм балигъ булырга тиеш. Имам Әбу Хәнифә (рәхимуллаһ) балигъ булмаганнар һәм акыллары зәгыйфь кешеләр, гошердән кала, зәкят түләргә тиеш түгел дип исәпләгән. Аларның опекуннары да шулай ук алар милкеннән зәкят түләргә тиеш түгел [1].

Бу фикер түбәндәге - Әбу Давыд, Нәсаи һәм башкалар ышанычлы дәвамлылык (иснәд) буенча тапшырылган хәдискә таяна.

Гайшә (радыйаллаһу ганһа) әйтүенчә, Аллаһы Тәгалә илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам): "Каләм баланың балигъ булганчы, йоклаучының уянганчы, акылдан язганның терелгәнче кылган гамәлләрен язмый" [2], - дигән.

Бу хәдистәге "каләм күтәрелгән" сүзләре җаваплылыкның юк икәнлеген аңлата.

Күпчелек галимнәр хәнәфиләр фикеренә каршы башка хәдисне китерә. Ләкин Тирмизи бу хәдис турында үз китабында болай ди: "Бу хәдис (буыннан-буынга тапшырылса да), ышанычлы түгел. Бу иснәдтә хәл ителмәгән мәсьәлә бар, чөнки иснәднең бер тапшыручысы Мусанна ибн ас-Сабах көчсез рави (тапшыручы) дип исәпләнелә. Кайберәүләр бу риваятьне Гомәр (радыйаллаһу ганһу) сүзләре дип тапшырганнар" [3]. Камал Ибн Һәммам "Фатхуль-Кадир" китабында бу хәдиснең нигезләре турында сөйләгәндә, аны дәлил буларак кулланының дөрес булмавы турында яза. Шуннан соң ике якның да карашларын дәлилләүче сәхабәләр фикерләренең булуын исәпкә алып, бу сорауга кыяс күзлегеннән чыгып карый [4].

Имам Мөхәммәд (рәхимуллаһ) "Китәбүл-Асл" хезмәтендә, бу сорауга аңлатмалар биреп, болай ди: "Намаз алар өчен фарыз түгел, шуңа күрә зәкят тә түләнергә тиеш түгел" [5]. Шулай ук ул бу сорауда капма-каршы фикерләрне җиткергән китаплар булуы турында да әйтә һәм бу очракта кыяска таянырга киңәш итә. Кыяс буенча зәкят гыйбадәт кылуга тиң, димәк, гыйбадәт кылырга тиеш булмаганнар зәкят түләргә дә тиеш түгел.

Бохари тапшырган һәм күп кенә хәдисләр җыентыкларында китерелгән хәдис: "Ислам биш баганага таяна". Бу хәдистә ислам диненең нигезләре санап үтелгән һәм аларның барысын да балигъ, үз акылында булган кеше үтәргә тиешле булулары берләштерә. Ә балага яки зәгыйфь акыллы кешегә аларны үтәү мәҗбүри түгел. Шул рәвешчә, зәкят өчен иң яхшы чагыштыру (кыяс) булып, намаз һ. б. гыйбадәт кылу төрләре тора.

Намаз кебек үк, зәкят - гыйбадәт кылу нигезләренең берсе. Ә гыйбадәт кылу нияттән башка булмый. Балалар һәм зәгыйфь акыллы кешеләрнең нияте дөрес була алмый, чөнки аларның дөрес ният белән тиешле гыйбадәт кылу хәлләреннән килми. Нәкъ менә шул сәбәпле алар өчен гыйбадәт кылу мәҗбүри түгел. Ниятсез намаз дөрес булмаган кебек, зәкят тә алар өчен мәҗбүри түгел.

Күпчелекне тәшкил итүчеләрнең фикере балигъ булмаганнар һәм акыллары зәгыйфь кешеләрнең дә милкеннән зәкят түләнергә тиеш диюендә балигъ булу һәм үз акылында булу зәкятнең шартлары булып тормый. Аларның милкеннән зәкятне опекуннары яки варислары түләргә тиеш. Опекун аның карамагында булган туганнарына тиешле яшәү шартлары тудырырга тиеш булган кебек, алар милкеннән зәкят түләү дә аның өстендә. Алар исеменнән опекун әйткән ният аларның да нияте дип санала [6].

Акылы зәгыйфь кешеләр ике төрле була.

Беренчесе: зәгыйфь акыл белән туып, шул рәвешле балигъ булып, гомерләре буенча зәгыйфь акыл белән яшәүче кешеләр.

Икенчесе: балигъ булгач акылын югалткан кеше.

Имам Мөхәммәд (рәхимуллаһ) фикеренчә, бу ике төр акылы зәгыйфь кешеләргә карата да ике төрле карар чыгарырга була:

а) дәвалап бетереп булмый торган акылдан язу. Мондый кешеләр милкеннән, хәнәфи мәзһәбе буенча, зәкят түләү важиб түгел [7];

б) дәвалап була торган акылдан язу. Биредә сүз вакыт-вакыт акылларын югалта торган кешеләр турында бара. Бу төр акылдан язу шәригать тарафыннан авыру буларак кабул ителми, шуңа күрә кеше зәкят түләргә тиеш. Ләкин акылдан язу бер ел дәвам итсә, бу дәвалап булмый торган акылдан язуга керә һәм зәкят түләү бу кешегә фарыз булмый.

Имам Мөхәммәд (рәхимуллаһ) бу ике фикерне дә кабул итә, ә имам Әбу Йосыф (рәхимуллаһ) дәвалап була торган акылдан язу очрагының икенчесен генә исәпкә алган [8].

Шулай итеп, елның бер өлешен үз акылында булып, икенчесен акылдан язган халдә яшәгән кеше зәкят түләргә тиешме дигән сорау туа.

Бу очракта ике риваять бар. Беренче - имам Мөхәммәд риваяте (надир әр-ривая) буенча, әгәр дә кеше елның кыска гына бер өлешен үз акылында үткәргән икән, аның өчен закят түләү фарыз. Бу риваятьне шулай ук Ибне Сәма һәм Әбу Йосыф тапшырган.

Икенче, Әбу Йосыф (рәхимуллаһ) һәм аның шәкерте Һишам тапшырган, риваять буенча, әгәр дә кеше елның күпчелек өлешен үз акылында үткәргән икән, аның өчен зәкят түләү мәҗбүри.

[1] Әбу Бәкер Мөхәммәд ибн Әхмәд Шәмсел-Әиммә әс-Сәрхаси, әл-Мәбсүт; Галәведдин Әбу Бәкер әл-Касани, Бадаигус-Санаиги фи Тартибиш-Шараиг.
[2] Әбу Давыд, Китәбүл-Худүд, бәб филь-мәҗнүни йасрику.
[3] Тирмизи, әз-Зәкят, бәб зәкәтү мәлил-ятим.
[4] Камал Ибнел-Һәммам, Фәтхел-Кадир.
[5] Әбу Абдилляһ Мөхәммәд ибн әл-Хәсән әш-Шәйбани, Китәбүл-Әсл 2/11.
[6] Әс-Сәрхаси, әл-Мәбсүт, 2/162, 163.
[7] Камал Ибнел-Һәммам, Фәтхел-Кадир, 1/484.
[8] Камал Ибнел-Һәммам, Фәтхел-Кадир, 1/484.
[9] Галәведдин Әбу Бәкер әл-Касани, Бәдаигус-Санаиги фи Тартибиш-Шараиг.

**Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

# РАМАЗАН АЕНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Кадер кичәсе тын һәм нурлы була. Кадер кичәсендә йолдызлар да атылмый. Кадер кичәсеннән соң килгән көннең кояшы артык якты булмый.

Ул кичәдә фәрештәләр Аллаһның рәхмәтен таратырлар, шайтан да үзенең мәкерлеген кыла алмас. Гайшә анабыз (Аллаһ аннан разый булса иде!) Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән сораган: "Йә рәсүлебез, әгәр мин Кадер кичәсенә ирешсәм, миңа ничек дога кылырга?" Аллаһның рәсүле галәйһиссәлам әйткән: "Аллаһүммә иннәкә гафуун түхиббүл гафвә фәгъфу ганни. (Әй Аллаһым, Син гафу итүче, Син гафу итәргә яратасың - гафу ит мине, гөнаһларымны ярлыка), - дип дога кыл".

Хөрмәтле мөселманнар! Рамазан аеның санаулы көннәре калды, Аллаһы Раббыбыз шушы көннәрдә изге гамәлләребезне күбрәк кылуны насыйп итсә иде. Ибне Габбас дигән сәхабә (Аллаһ аннан разый булса иде!) әйткән: "Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кешеләрнең иң юмарты иде һәм рамазан башланса, аның иң юмарт вакыты башлана иде", - дигән. Гайшә анабыз (Аллаһ аннан разый булса иде!) әйткән: "Рәсүлебез иң юмарт кешеләрдән иде. Иң юмарт вакыты рамазанда башлана иде, һәр богаулыны азат итә иде һәм һәр сораучыга бирә иде".

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: "Аллаһ юмарт һәм Ул юмартлыкны сөядер". Икенче хәдис-шәрифтә: "Иң хәерле сәдака - ул да булса рамазан сәдакасыдыр", - дип әйтелгән.


Бөтен дөнья мөселманнары изге Рамазан аенда пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнән үрнәк алып, кешеләрне авыз ачтыралар, ифтар мәҗлесләре үткәрәләр. Искә төшерик, мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: "Кем дә кем ураза тотучыны авыз ачтырса, шул кеше күпме ураза тотучыны ашаткан булса, аларның бөтенесенең дә әҗерләрен үзенә алыр, шуның өстәвенә ураза тотучыларның да әҗерләре кимемәс". Икенче хәдистә: "Рамазан аенда ураза тотучыны авыз ачтырсаң, ул синең гөнаһларыңа кәффарәт булып, уттан котылуыңа сәбәп булыр", - диелгән. Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бу сүзләрен ишеткәч, бик тәэсирләнгәннәр, тик бөтенесенең дә авыз ачтыртып ураза тотучыларны ашатырга хәленнән килмәгәнлектән, бу турыда алар Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) әйткәннәр. Рәсүлебез галәйһиссәлам аларга: "Нияте изгедә булып, ураза тотучыны бер хөрмә яки бер йотым су белән булса да авыз ачтырсагыз, сез шундый ук әҗер алырсыз, бу изге эшегез өчен Раббыгыз сезне Кыямәт көнендә шундый су эчерер, бәндәнең җәннәткә кергәнчегә хәтле башка бер дә эчәсе килмәс", - дигән.

Газиз дин кардәшләрем! Нәфескә каршы торып, рамазанның соңгы көннәрен игелекле гамәлләребез, нәфел гыйбадәтләре, зикерләр, тәүбәләребез белән бизик, Аллаһның рәхмәтеннән, мәгъфирәтеннән (ярлыкавыннан. - Ред.) мәхрүм булмыйк.

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге***

# ФИТЫР СӘДАКАСЫ НӘРСӘ УЛ ҺӘМ АНЫ БИРҮ КЕМНӘР ӨЧЕН МӘҖБҮРИ?

**Сорау. Фитыр сәдакасы нәрсә ул һәм ул нинди күләмдә бирелергә тиеш?**



**Җавап.** Зәкят кебек үк, фитыр сәдакасы да, Аллаһка табынуның матди чыгымнар сорый торган төре. Сәдаканың бу төре рамазан ае тәмамлангач үткәрелә торган Ураза бәйрәме белән бәйле рәвештә бирелергә тиеш. Аның исеме шуннан - бәйрәмнең гарәпчә атамасыннан алынган.

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде!) хәдисендә килгән рәвештә фитыр сәдакасы мөселманнардан булган ирекле кешеләргә - бар ир-ат һәм хатын-кызларга, кечесенә һәм өлкәненә, гает алды көнендә, бәйрәм намазына чыгар алдыннан, бер сагъ (якынча тугыз кадак ясмык сыярлык савыт) тулысынча хөрмә, яки арпа, яки йөзем, яки ярты сагъ бодай (яисә он) бирергә кушкан. Бу мәсьәләгә халкыбызның бөек галиме, мәгърифәтче Ш.Мәрҗани дә үзенең гыйльми хезмәтләрендә тукталып үтә. Мәрҗани хәзрәтләре үзенең матди ярдәмчеләре булган кайбер байларга шөбһә һәм ихтилафтан чыгар өчен бер сагъ хөрмә яки илебездә бер сагъ хөрмә күпме торса, шулкадәр акчаны сәдака итеп бирергә кирәклеген аңлаткан.

Фитыр сәдакасы бирү важиб гамәлләрдән санала.

Билгеләнгән акча һәм мөлкәт минимумына ия булган һәр мөселманга фитыр сәдакасы бирү мәҗбүри. Акча һәм мөлкәтнең әлеге минимумы кешенең кичектергесез ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен зарур булган суммадан (мәсәлән, бурычларны түләү, аның каравында булган кешеләрнең кичектергесез ихтыҗларын канәгатьләндерү) чыгып билгеләнә.

Зәкяттән аермалы буларак, акылга зәгыйфь булмау, балигъ булу - фитыр сәдакасы бирү өчен шарт итеп куелмый. Мәсәлән, балигъ булмаган балаларның, акылга зәгыйфь кешеләрнең тиешле күләмдәге мөлкәтләре бар икән, аларны караган кешеләр алар исеменнән фитыр сәдакасы бирергә тиешләр. Әгәр дә бу кешеләр моны эшләмиләр икән, бу бала кеше эшләнми калдырылган бу эшне үзе балигъ булгач башкарырга тиеш, ә акылга зәгыйфь булган кеше - үз акылына кире кайтса.

Үз акылында булган өлкән кешеләр фитыр сәдакасын үзләре өчен генә түгел, ә аларның тиешле дәрәҗәдәге үз мөлкәтләре булмаса, үзенең балигъ булмаган балалары өчен дә бирергә тиешләр. Балигъ булган балаларга килгәндә, алар моны, алар акылга зәгыйфь булса яки аларның тиешле мөлкәте булмаган очракта гына башкарырга тиешләр. Әгәр дә гаиләдә әти кеше юк икән, бу бурычны башкару гаилә башлыгына йөкләнә.

Гаиләдә ир кеше үзенең хатыны өчен фитыр сәдакасы бирергә тиеш түгел, чөнки хатынының финанс һәм мөлкәт эшләренә аның хокуклары юк. Шулай ук, үзенең үз акылындагы үсеп җиткән улы өчен дә ул бирергә тиеш түгел, чөнки аның бу улы өстеннән, ул балигъ булуыннан соң, хокукы тулы булып санала алмый. Шулай итеп, мөэмин-мөселман кеше үз тәрбиясендә булган һәркем өчен дә фитыр сәдакасы бирергә тиеш.

"Фитыр сәдакасы сыйфатында, гадәттә, берешәр сагъ ниндидер ризык яки берешәр сагъ коры эремчек яки берешәр сагъ йөзем җимеше бирәләр", - дип килә Әл-Бохари сахихендә.

Ярты сагъ бодай 2-2,5 килограммга тиң. Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фәкыйрьләргә моны, бодай урынына, аның акчалата нисбәтендә бирергә мөмкин дип исәплиләр. Алар моны сәдака бирүнең фәкыйрьләрне ифтар көнендә мохтаҗлыкта калдырмас өчен эшләнүенә нигезли, ә аларның ул мохтаҗлыгы бер ризык кына булмаска мөмкин. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде!) әйткән: "Бу көнне аларны кешеләрдән (соранып) йөрү зарурлыгыннан коткарыгыз" (Әт-Дара Кутни; бине Ади; әл-Хәким). Менә ни өчен факиһлар мохтаҗларга фитыр сәдакасын дирһәмнәрдә бирүне яхшырак та дип исәпли.

Фитыр сәдакасы бирү - мөселманнарның гомер буе башкарылырга тиешле бурычы. Моны бәйрәм көнендә таң атканчы яки таң аткач та эшләргә була, чөнки фитыр сәдакасы өчен күрсәтмәләр, зәкят күрсәтмәләре кебек үк, абсолют характерда. Безнең көннәргә килеп җиткәнчә, Ибне Гомәр фитыр сәдакасын аны алучыларга тараткан. Алар (сәхабәләр) фитыр сәдакасын бәйрәмгә кадәр бер-ике көн алдан биргәннәр (әл-Бохари сахихе).

Фитыр сәдакасын көнендә бирә алмый калу - аны башкару бурычыннан азат итми, ул аны соңлап булса да бирергә тиеш, тик бу юлы аның савабы азрак була.

Һәркем бер яки берничә мохтаҗ кешегә фитыр сәдакасы бирергә мөмкин, тик аларның һәрберсе дә акчалата нисбәттә тулы күләмдә булырга тиеш.

Зәкят рәвешендә җыелган финанс һәм матди кыйммәтләрдән ярдәм алырга хокуклы кешеләр фитыр сәдакасы алырга да хокуклы.

Быел рамазан аеның ахыргы көне 7 нче августка туры килә. Ураза тәмамлану белән, мөселманнар 8 нче август көнне Ураза бәйрәмен билгеләп үтәчәк. Аны халык Рамазан гаете дип йөртә. Гает көнне иртән хәллерәк, акчалырак кешеләр фәкыйрьләргә һәм мохтажларга, ятимнәргә фитыр сәдакасы өләшә. Фитыр сәдакасын иртәрәк тә бирергә мөмкин.

Фитыр сәдакасының мәгънәсе - Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде!) хәдисләре буенча аңлашылганча, ураза тотучының уразасы кимчелекләрдән пакьләнеп, Аллаһ каршысында тулысынча кабул ителүен өмет итеп бирелә торган сәдакадыр. Гадәттә, гаилә башлыгы хатыны һәм балалары өчен дип сәдака бирә. Рамазан башланыр алдыннан гына бер бала туса, аның өчен дә фитыр сәдакасы бирү тиешле. Әгәр балалары үзләре эшләп акча таба яки аерым гаилә булып яши икән, алар фитыр сәдакасын үзләре түли. Быел фитыр сәдакасының күләме Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 50-300 сум дип билгеләнде.

Әнәс бине Мәликтән килгән хәдистә болай диелгән: "Рамазан уразасы җир белән күк арасында эленеп тора һәм фитыр сәдакасын биргәннән соң гына ул күкләргә ашачак" (Имам Дайлами).

# ИГЕЛЕК ИШЕКЛӘРЕ АЧЫК

**Быелгы рамазан ае Мамадышта һәм авылларда ифтар мәҗлесләренең күбрәк үткәрелүе белән аерылып тора.**



Элекке елларда теләкләре булганнар өйләргә чакыралар, бер тапкыр бөтен шәһәр мөселманнары өчен 2 нче лицейда оештырыла иде. Быел Ураза башланганнан бирле көн саен шәһәребез мәдрәсәсендә берничә кеше җыелышып авыз ачтыру, ифтар мәҗлесе үткәрү гадәткә кереп китте. Беренче булып аны өч көн рәттән мәслимәләрнең “Ак калфак” оешмасы җитәкчесе, эшмәкәр Розалия Ибраһимова оештырган иде. Кафеларга да мөрәҗәгать итүчеләр күп икән. Мөхтәсибәткә көн саен авыллардан да әллә ничә чакыру килә. Бу – халыкның дингә тартылуымы, әллә игелек кылырга омтылуымы? Ничек кенә булса да, икесе дә – хәерле. Якшәмбе көнне районыбыз җитәкчелеге һәм мөхтәсибәт унынчы тапкыр 2 нче лицейда ифтар мәҗлесе үткәрергә карар иткәч, аңа өч йөзләп мөселман чыкырылган булган. Мәҗлес башланырга ярты сәгать калгач, шәһәр өстендә көчле яңгыр яварга керешге, урамнар тулып ташу ага башлады. Дин юлына баскан әби-бабайлар, кечкенә малайлар-кызлар, яңгыр түгел, таш яуса да, мондый олы мәҗлесләрне калдырмаячакларын белдерде. Ураза тоту Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен башкарылса, Мамадышның үзәк мәчете имам-хатыйбы Наил хәзрәт Вахитов әйтмешли, “Ифтар мәҗлесе – рамазан аеның иң күркәм вакыты”. Җәй челләсе булгач, быел 18-19 сәгать тирәсе ашаудан тыелып торырга туры килә. Мәҗлеснең үзендә катнашуның да әҗере – савабы бар. Ураза бит ул ашаудан тыелып тору гына түгел, рухың пакьләнү дә. Аллага ышанган кеше генә аннан куркып, гөнаһ эшләүнең ярамаганлыгын аңлый башлый. Нәкъ менә изгелек, яхшылык эшләү берләштерә бит инде безне. Кылган яхшылыклар, җылы сүзләр араларны якынайта. Безнең буын үскәндә әби-бабайлар урак вакытында да ничек итеп ураза тотулары турында сөйли иде. Ифтар мәҗлесләре үткәрергә ирек бирмәгәннәр бит аларга, ашарларына рәтле-башлы ризыклары да булмаган. Кара ипи, кипкән кызыл чөгендер чәе, катык белән авыз ачып, шулар белән сәхәр ашап басуга киткәннәр. Хәзер кайсы гына ифтар мәҗлесендә катнашсаң да, өстәлләр сый-нигъмәтләрдән сыгылып тора. Быелгы рамазан аенда Мамадышка ямь өстенә ямь өстәп, Төркиядән ике коръәнхафиз килеп, көн саен берсе үзәк мәчеттә, икенчесе авылларда Корьәни-Кәримне күңелдән укый, вәгазьләр сөйли, мәҗлесләрдә катнаша.

2 нче лицейда үткән ифтар мәҗлесе дә аларның Коръән укуларыннан башланып китте. Казаннан да байтак кунаклар килгән иде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең дәгъвәт буенча урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров мөфти исеменнән дә тәбрикләү ирештерде. Ул да вәгазен рамазан ае нигъмәтләренә багышлады. Булачак коръәнхафиз Сәет Давытның Мөхәммәд пәйгамбәр Мәдинәгә кергәндә сәхәбәләре башкарган нашидне җырлавы ерак гасырларга алып киткәндәй булды. Дәгъвәт бүлегеннән Руслан хәзрәтнең: “Исламның нигезләрен яшьләр күтәргән. Хәзер дә безгә яшьләр кирәк. Әтиәни өчен беренче чиратта бала дога кылырга тиеш. Картайгач намазга басам диючеләр Аллаһны түгел, үз-үзләрен алдый”, – дигән сүзләре бәйрәмгә җыелган һәркем өчен искәртү булып яңгырады. Мамадыш муниципаль районы башлыгы Анатолий Иванов та үзенең чыгышында дини тәрбиянең яшь буынны тәбияләүдә аерылгысыз өлеш булуын ассызыклап үтте. Узган уку елында районыбыз җитәкчелеге мәктәпләрдә очрашулар оештырды, балаларга ислам һәм христиан диннәре буенча догалыклар өләшенде. “Балаларның дингә тартылуы сөендерә. Түбән Яке, Түбән Козгынчы, Көмешкүл кебек авыллар бигрәк тә аерылып тора. Элек районда балигъ булмаганнар тарафыннан ел саен егермешәр җинаять кылынган булса, былтыр берәү дә булмавында дини тәрбиянең дә йогынтысы бар. Быелның беренче яртыеллыгында да яшүсмерләр арасында җинаять кылучылар күзәтелмәде”, – диде районыбыз җитәкчесе. Якташларыбыз Миңгол Галиев белән Ильяс Халиков бәйрәмгә җыелучыларга мөнәҗәтләр, җырлар бүләк итте.

Бергәләп ахшам намазын укыганнан соң, тәбрикләүләр бәйрәм табыны артында дәвам итте. Олысы-кечесе аннан калебләре тагын да сафланып таралышты.

Ә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтеннән килгән кунаклар Казанга кайтышлый Уразбахты авылы мәчетенә кереп тәравих намазы укыганнар һәм вәгазь сөйләгәннәр.

**Фирая МИНГАЛИЕВА, Мамадыш**

# Төркиядән килгән коръәнхафиз – татар

**Республикабызга рамазан аенда Төркиядән коръәнхафизлар килде. Шуларның берсе - Кастамон шәһәрендә Имамнарның белемен күтәрү үзәге директоры булып эшләүче Мөхәммәт Озтүрк Әлмәт шәһәре Җамигъ мәчетендә дини эшчәнлек алып барырга булыша. Танышкач, сөйләшкәч шунысы билгеле булды: Төркиядә туып үскән дин әһеле татар булып чыкты, дип хәбәр итә Әлмәт мөхтәсибәте. Хәзрәт татарча яхшы белә. Үзенең әйтүенә караганда, Төркиядәге гаиләләрендә алар татарча гына сөйләшәләр икән. Аның бабалары Лениногорск районы Сарабиккол авылында яшәгән. XIX гасырда, кысрыклауларга һәм авырлыкларга түзә алмыйча, Төркиягә күченеп китәргә мәҗбүр булганнар.**



22 нче июль көнне Мөхәммәт хәзрәт Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов һәм мәчеткә йөрүчеләр белән бергә Сарабиккол авылына барды. Авыл зиратында, мәчеттә булдылар. Сарабикколның тарихы бик борынгы дәвергә барып тоташа, моны зираттагы каберташ язулары да раслый.

Әлбәттә, Мөхәммәт хәзрәт күңелендә бабалары яшәгән җирләргә басып йөрү кабатланмас тойгылар уятты. Әлмәт, Татарстан авыллары күңеленә хуш килде. Ул республика мәчетләрендә тәртип булуын, күп гасырлар дәвамында хәнәфи мәзһәбе өйрәтүләре саклануына шатлануын белдерде. Туган иленең (Төркиянең) Госман хәлифәте вакыты тарихын яхшы белгән хәзрәт, тәртип һәм тынычлыкны киләсе буыннарга тапшыруны бүгенге дин әһелләренең бурычы итеп күрә. Аллага шөкер, хәзерге вакытта тарихый-рухый мирасыбызны саклау юнәлешендә күп эшләр эшләнә, Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов җитәкчелегендә Әлмәт мөхтәсибәте, районның бар мәчетләрендә мөселманнар әлеге җирлектә тату яшәсен өчен, зур тырышлык куя.

**Чыганак: www.dumrt.ru.**

### УРАЗАНЫ БОЗУЧЫ, КӘФФАРӘТ (КЫЛЫНГАН ГӨНАҺЛАРДАН КОТЫЛУ ГАМӘЛЛӘРЕ) ҺӘМ КАЗА КЫЛУНЫ ТАЛӘП ИТҮЧЕ ГАМӘЛЛӘР

Бу дөньяда барысына да, Хисап көнендә иманлыларга гына рәхим-шәфкатьле Аллаһ исеме белән.

Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

Әгәр дә кеше уразага кереп, аннан соң аны азык, су, дару кабул итү, тәмәке тарту яки җенси якынлык кылу сәбәпле аңлы рәвештә боза икән, ул зур гөнаһ кылган булып исәпләнә. Бу кешегә бозылган бер көн уразасы өчен тагын бер көн ураза тоту белән каза кылу зарур. Моннан тыш, кәффарәт тә таләп ителә. Бу очракта 60 көн рәттән ураза тоту кәффарәт була. Әгәр нинди дә булса берәр сәбәп белән кәффарәт бозылган яисә тулысынча башкарылмый калган икән, кәффарәтне яңадан башлап, яңа баштан 60 көн рәттән ураза тотарга кирәк. Кәффарәт уразасы тотучы хатын-кызлар айлык күрем көннәрендә ураза тотмый. Күрем көннәре беткәч, алар янәдән бер көн дә калдырмыйча кәффарәт уразасын тотуны дәвам итәләр.

Кәффарәт, уразаны аңлы рәвештә бозган өчен, бу дөньяда җәза алу булып тора (Кара: Зур ислам энциклопедиясе. Гомәр Бильмен).

Аллаһка яхшырак мәгълүмдер.

***УРАЗА ТОТКАНДА УКОЛЛАР КАДАТЫРГА ЯРЫЙМЫ?***

Имам Әгъзам Әбу Хәнифәнең фикере буенча, уколлар уразаны боза. Моның өчен, бу кеше кәффарәтсез генә каза кылырга тиеш. Ике имам - Мөхәммәд һәм Әбу Йосыф фикере буенча, уколлар уразаны бозмый. Ләкин, ялгышларга юл куймау максатларында, фәтва имам Әгъзам (Әбу Хәнифә) фикере буенча чыгарыла, ягъни уколлар уразаны боза (Кара: Тәхтәви әля Маракил Фәлях. - Б. 542-546; Фәтава әл-Һиндия. - Т. I. - Б. 302-305).

Аллаһка яхшырак мәгълүмдер.

# ИГЪТИКЯФ

**Бу дөньяда барысына да, Хисап көнендә иманлыларга гына рәхим-шәфкатьле Аллаһ исеме белән.**

Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

Мәчеттә берүзең генә калуны игътикяф диләр. Хәнәфи мәзһәбе буенча, **игътикяфның өч төре була.**

**Беренче төре** - әйтелгән нәзер буенча важиб гамәл кылу. Мәсәлән, кем дә булса: "Нинди дә булса эш хәл кылынса, мин фәлән көн игътикяф кылырмын яки мин, һичшиксез, ничәдер көн игътикяф кылырмын", - дип әйтсә, бу аның өчен важибкә әйләнә. Бу очракта, ничә көнгә нәзер әйтелгән булса, шул кадәр үк көн игътикяф кылырга кирәк.

**Икенче төре** - рамазан аеның соңгы ун көнендәге сөннәт игътикяф.

**Өченче төре** - нәфел игътикяф. Аның өчен нинди дә булса вакыт билгеләнмәгән һәм аның срогы буенча да чикләүләр юк. Кеше бар гомере буена игътикяф кылырга да ният кылырга мөмкин. Ләкин игътикяф кылуның иң кыска вакыты буенча төрле фикерләр бар. Мәсәлән, имам Әбу Хәнифә (рәхмәтуллаһи гәләйһи) фикере буенча, бер көннән дә кимрәк вакытка ният кылмаска кирәк. Ә имам Мөхәммәд (рәхмәтуллаһи гәләйһи) фикере буенча, бик кыска гына вакытка да ният кылырга була. Моның өчен фәтва бар. Шуңа да, мәчеткә кергән вакытта, һәр кешегә, ул мәчеттә намаз укыган яки Аллаһка башкача табынган вакытта, игътикяф савабын алу өчен, игътикяфка ният кылып керергә кирәк. Игътикяфның савабы зур. Аллаһның Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) үзе моны гел башкара торган булган. Бу гамәлнең кыйммәтлеген раслаучы тагын да нинди дәлил булырга мөмкин?



Безнең көннәргә кадәр килгән мәгълүматлар буенча, әгәр дә игътикяфны ихлас кылсаң - ул иң изге гамәлләрнең берседер. Ул үз күңелең белән бергә-бер калу, бу дөньядан, анда булганның барыннан да читкә китеп тору. Игътикяф вакытында кеше гел Аллаһка табыну белән мәшгуль. Ул йокы халәтендәме, әллә инде уяумы - барыбер, Аллаһка табыну, Аллаһка якынаю халәтендә. Кодси хәдисләрнең берсендә болай диелә: "Әгәр кеше Минем бер уч төбе кадәр якынайса, Мин аның бер кулы кадәр якынаермын. Әгәр Миңа атлап килсә, Мин аңа йөгереп килермен". Игътикяф вакытында кеше "Аллаһның кунагы" була һәм юмарт Хуҗа үзенең бу кунагын һәрвакыт каршы ала. Ул Аллаһның ныклыгы сагында һәм дошманы аңа һөҗүм итә алмый. Аллаһка табынуның бу мөһим төренең башка күп кыйммәтлекләре һәм үзенчәлекләре бар...

Ир-атлар өчен игътикяф өчен иң кулай урын - Мәккәдәге мәчет, ә аннан кала - Мәдинәдәге мәчет. Аннан соң - Бәйтел Мөкаддәс мәчете, аңардан соң - Җамигъ мәчет, ә аннан соң - үз мәхәлләң мәчете. Әбу Хәнифә буенча, игътикяф кылган вакытта биш вакыт намаз укылырга тиеш дигән шарт бар. Имам Мөхәммәд һәм Әбу Йосыфларның фикере буенча, игътикяф кылу өчен, анда җәмәгать белән намаз укулар булмаса да, шәригать кануннарына туры килүче мәчет булуы да җитә. Хатын-кыз үз өй эчендәге мәчеттә игътикяф кыла ала. Әгәр өйдә мәчет өчен урын билгеләнмәгән булса, аңа өйдә нинди дә булса бер урынны сайлап алырга кирәк (Кара: Зур ислам энциклопедиясе, Гомәр Нәсүхи Бильмен).

Аллаһка яхшырак мәгълүмдер.


«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 5 (200) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35414.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 1 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**